| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 03.06.2022 | Буа шәһәре | № 147/Бк/к |

2022 елның II кварталына торак урынның гомуми
мәйданының бер квадрат метры бәясе турында

«Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү «Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган аерым чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2022 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе нормативы һәм 2022 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2002 елның 17 декабрендәге 955/пр боерыгы нигезендә, «Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр союзы» коммерциясез партнерлыгының 2002 елның 08 февралендәге 47 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» тикшеренү нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 нномерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның II кварталына яшь гаиләләргә торак сатып алуга яисә индивидуаль торак йорт төзүгә социаль түләү күләмен исәпләп чыгару өчен Буа муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры нормативын 34 589,00 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов